КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 5 март г.Казань № 198

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында санитария-эпидемиология хәлен һәм яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу үзенчәлекләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 18 февраль, 136 нчы; 2022 ел, 26 февраль, 169 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктның бишенче – унынчы абзацлары үз көчен югалткан дип танырга;

5 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктның «д» пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

7 пунктта «COVID-19 яңа коронавирус йогышлы авыруына каршы вакцинация ясаган яки соңгы алты айда әлеге авыру белән авырган» сүзләрен төшереп калдырырга;

8 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымтаның 1 пунктында:

7 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

14 пунктча үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин